**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2017 ел, 8 ноябрь

№ 849

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт финансларын савыктыру чаралары планын раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1194 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт финансларын савыктыру чаралары планын раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1194 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 14 гыйнвар, 8 нче; 2013 ел, 30 сентябрь, 701 һәм 2015 ел, 9 февраль, 74 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының Россия Федерациясе алдындагы бюджет кредитлары буенча йөкләмәләрен (бурычларын) реструктурлаштыру тәртибе һәм өстәмә шартлары турында» 2012 ел, 18 декабрь, 1325 нче карары белән расланган Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе алдындагы йөкләмәләрен (бурычларын) реструктурлаштыру кагыйдәләренең 13 нче пунктындагы «а» пунктчасы һәм «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2017 елда Россия Федерациясе субъектларының Россия Федерациясе алдындагы бюджет кредитлары буенча йөкләмәләрен (бурычларын) реструктурлаштыру тәртибе һәм өстәмә шартлары турында, шулай ук «2017 елга һәм 2018 һәм 2019 еллар план чорына федераль бюджет турында» Федераль законның 16 статьясындагы 5 өлештә күрсәтелгән Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары чыгымнарын билгеләү тәртибе турында» 2017 ел, 30 сентябрь, 1195 нче карары белән расланган 2017 елда Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе алдындагы йөкләмәләрен (бурычларын) реструктурлаштыру

кагыйдәләренең 15 нче пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 нче пункттагы «2017 елга кадәр» дигән сүзләрне «2020 елга кадәр» дигән сүзләргә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган 2017 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасы дәүләт финансларын савыктыру чаралары планын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\849.docx